# БЕЛДЕРҮ

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.18 статьясы нигезендә һәм гражданнан җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында гаризасы килүгә бәйле рәвештә Кукмара муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы (алга таба – Палата) шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен, милеккә түбәндәге характеристикалы җир кишәрлеген (алга таба шулай ук – сорала торган җир кишәрлеге) бирү мөмкинлеге турында хәбәр итә:

Кадастр кварталы 16:23:060601, мәйданы 1435 кв.м, җир категориясе: «торак пунктлар җирләре», рөхсәт ителгән файдалану төре: «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен», кишәрлекнең урнашкан урыны: Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Березняк авыл җирлеге, Аман-Оштырма авылы, Ленин урамы, 44а җир кишәрлеге. Әлеге белдерүгә территориянең кадастр планында җир кишәрлегенең урнашу схемасы кушып бирелә.

Палата сорала торган җир кишәрлегенең төзелергә тиешлегенә игътибар итә.

Югарыда күрсәтелгән җир кишәрлеген милеккә алырга кызыксынучы гражданнар аукционда катнашу нияте турында әлеге хәбәр басылып чыкканнан соң 30 көн эчендә бирергә хокуклы. Гаризаны гариза бирүче (гариза бирүченең ышанычлы заты) эш көннәрендә (дүшәмбе – җомга, эшләми торган бәйрәм көннәреннән, эшләми торган көннәр дип игълан ителгән көннәрдән, ял көннәре күчерелгән көннәрдән тыш) 8.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр (12.00 сәгатьтән сәгать 13.00 гә кадәр – төшке аш өчен тәнәфес) Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Кукмара шәһәре, Ленин ур., 15 йорт, 101 нче бүлмәгә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә тапшыра ала. Гариза һәм аңа кушылган документларны электрон документ формасында тапшырганда, гариза бирүче (гариза бирүченең ышанычлы кешесе) Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгының «Җир кишәрлегенең яки җир кишәрлекләренең территориянең кадастр планында урнашу схемасын раслау турында гаризалар, дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлеген сату буенча аукцион яки дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлеген арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион үткәрү турында гариза, дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гариза, дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлеге бирү турында гариза, һәм дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен, шәхси милектә булган җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында гаризаларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен кулланып, электрон документлар формасында бирү тәртибен һәм ысулларын, шулай ук аларның форматына таләпләрне раслау турында» 2015 елның 14 гыйнварындагы 7 номерлы боерыгыhttps://login.consultant.ru/link/?req=doc&base=LAW&n=175784 таләпләрен үтәүне, «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законhttps://login.consultant.ru/link/?req=doc&base=LAW&n=453313 таләпләре нигезендә гаризаны һәм башка документларны имзалауны (раслау) тәэмин итә.

Гаризаларны кабул итү тәмамлану датасы – 2026 елның 30 апреле, 15 сәгать 00 минут.